Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты
422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27

тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
«город Арск» Арского
муниципального района Республики
Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская , 27

тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

« 29 » июнь 2020 ел    № 53

**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 250 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында парковкалар (парковка урыннары) булдыру, шул исәптән түләүле нигездә, һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Арча районы прокурорының 2020 елның 16 апрелендәге 02-08-02/7220 номерлы дәгъвасы, 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында"гы Федераль законның 8 статьясы нигезендә Арча шәһәре Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 250 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында парковкалар (парковка урыннары) булдыру, шул исәптән түләүле нигездә, һәм куллану тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 бүлекнең 3 пунктында "10" санын "15" санына алмаштырырга;

6 бүлекнең 6 пунктындагы 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "I, II төркем инвалидлар, шулай ук III төркем инвалидлар, һәм әлеге инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртүче транспорт чаралары. Әлеге транспорт чараларында федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә бирелгән "Инвалид" тану билгесе булырга тиеш.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты житәкчесенең гомуми мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәр башкарма
комитеты рәисе Р.Ф.Касимов